**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 10 «24» апрель 2026 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 13 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 15 декабрендәге 471-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 13 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә (11.11.2016 № 18, 25.09.2017 № 21, 15.02.2018 № 4, 16.12.2019 № 51, 30.01.2020 № 3, 24.04.2020 №19, 17.09.2021 № 35, 27.02.2023 № 12, 27.10.2023 № 46, 14.02.2024 № 4, от 18.11.2024 № 46, 05.06.2025 № 18, 24.10.2025 № 11 карарлар редакциясендә) 5 бүлегенең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәп, үзгәреш кертергә:

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарына (программаларына) кертелгән унитар предприятиеләрнең, акционер җәмгыятьләрнең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең әлеге пунктта каралган аралык бухгалтерлык (финанс) хисабы бухгалтерлык (финанс) хисабының дәүләт мәгълүмат ресурсын булдыру максатларында тапшырылырга тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов